ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

18.07.2022 г. Иннополис №54

Муниципаль милекне арендага бирү, торглар үткәрмичә түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында «Федераль законга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән берничә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында «Федераль законга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 19 июлендәге 204-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль милекне арендага бирү, торглар үткәрмичә түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Интернет челтәрендә Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), шулай ук Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иннополис шәһәре Башкарма комитетының финанс бүлеге начальнигы-Астраханцева Светлана Витальевнага йөкләргә.

Җитәкче: И.Р. Хуззятов